| | |
|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 2017 ел, 17 февраль | № 89 |

г. Казань

«Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен, «Түбән Кама технология көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен һәм «Түбән Кама нефть химиясе көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү тармаклары өчен квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр һәм урта звено белгечләрен әзерләү программасы сыйфатын күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумы), «Түбән Кама технология көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Түбән Кама технология көллияте) һәм «Түбән Кама нефть химиясе көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Түбән Кама нефть химиясе көллияте) кушу рәвешендә, алар нигезендә «Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте) төзеп, аларның төп эшчәнлек максатларын саклап үзгәртеп оештыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгене билгеләргә:

гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсеннән, Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты карарлары белән ел саен раслана торган урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнардан һәм һөнәри белем бирү оешмалары мөлкәтен карап тоту нормативларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

норматив хокукый актларда каралган үзгәртеп оештыру чараларын үткәрүне тәэмин итәргә;

2016/2017 уку елы тәмамлангач, Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумында, Түбән Кама технология һәм Түбән Кама нефть химиясе көллиятләрендә укучыларны әти-әниләре (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумында, Түбән Кама технология һәм Түбән Кама нефть химиясе көллиятләрендә гамәлдә булган укыту шартларын һәм программаларын саклап, Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә күчерергә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

30 көн эчендә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумының, Түбән Кама нефть химиясе көллиятенең Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә бирелергә тиешле мөлкәте исемлеген, шулай ук Түбән Кама технология көллиятенә оператив идарә хокукында беркетелгән күчемле һәм күчемсез мөлкәттән алга таба файдалану ихтыяҗы турында тәкъдимнәр кертергә;

Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен эшләргә;

Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятендә укучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

60 көн эчендә Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте уставын эшләргә һәм расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллияте уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң:

30 көн эчендә Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә оператив идарә хокукында аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган, элек Нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумына, Түбән Кама нефть химиясе көллиятенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне беркетергә;

120 көн эчендә Н.В.Лемаев исемендәге нефть химиясе һәм нефть эшкәртү көллиятенә беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, 2-5 нче пунктларны үтәгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын билгели торган норматив хокукый актларга аларны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\89.doc